РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.09.2020 1225-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 октябрендәге 1282-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренен өстәмә социаль ярдәмгә мохтаж укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне түләүсез оештыру рәвешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын түләүсез туклану белән тәэмин итү турында” 2019 елның 22 октябрендәге 1282-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең өстәмә социаль ярдәмгә мохтаж укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1-3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Әлеге Нигезләмә, башлангыч гомуми белем алучы балалар, гаиләсендә 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләнә торган күпбалалы гаиләләрдән булган 5-11 сыйныф укучылары һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучы балаларны кайнар ризык белән тәэмин итүне түләүсез оештыру рәвешендә, шулай ук өйдә белем алучы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучы балалар статусына ия булган инвалид балаларга азык-төлек җыелмасын түләүсез бирү рәвешендә, социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен билгели.

2. 1-4 сыйныф укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына түләүсез оештырыла.

3. Гаиләсендә 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләнә торган күпбалалы гаиләләрдән булган 5-11 сыйныф укучылары һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучы балаларга кайнар ризык, уку чорында, бер укучыга ,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчасы хисабына кайнар иртәнге аш һәм төшке аш рәвешендә бирелә. Туклану бәясе Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.”.

**2.** Әлеге карарның гамәлдә булуын 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

**3.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов